Казан шәһәре
Башкарма комитетының
________ № ______________
карарына кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының телләрне үстерү һәм иҗтимагый оешмалар белән үзара бәйләнешләр бүлеге**
**НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының телләрне үстерү һәм иҗтимагый оешмалар белән үзара бәйләнешләр бүлеге (алга таба – бүлек) Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппаратының структур бүлекчәсе (алга таба – Башкарма комитет Аппараты) булып санала.

1.2. Бүлек үз эшчәнлеген Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе, Башкарма комитет Аппараты җитәкчесе җитәкчелегендә алып бара. Бүлекне бүлек башлыгы җитәкли. Бүлек турындагы нигезләмә Башкарма комитет Аппараты җитәкчесе тарафыннан раслана.

1.3. Бүлек үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президентының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының хокукый актларына, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларына, шулай ук әлеге нигезләмәгә таяна.

1.4. Бүлек җирле үзидарә органнарының милли-мәдәни, дини һәм сәяси оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге эшчәнлеген координацияли.

## II. Бүлекнең максаты, бурычлары һәм эшчәнлек функцияләре

2.1. Бүлек эшчәнлеге предметы булып Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының милли-мәдәни, дини һәм сәяси оешмалар (алга таба – иҗтимагый оешмалар) белән элемтә һәм үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү тора һәм түбәндәге максатларга нигезләнә:

- иҗтимагый-сәяси, дини, тел һәм милли сәясәт өлкәсендәге законнарны гамәлгә ашыру;
- аларның иҗтимагый-файдалы һәм социаль әһәмиятле эшчәнлегендә кирәкле ярдәм күрсәтү;
- конфессияара һәм милләтара аңлашуга һәм татулыкка ярдәм итү;
- иҗтимагый-сәяси вәзгыятьтә тотрыклылыкны саклау;
- Казан шәһәрендә яшәүче халыкларның телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү.

2.2. Максаткларга таянып бүлек түбәндәге бурычларны һәм функцияләрне башкара:

- Башкарма комитетның иҗтимагый оешмалар һәм аларның вәкилләре белән үзара кызыксынуы булган мәсьәләләр буенча даими элемтәләрен һәм үзара хезмәттәшлеген үтәлешен тәэмин итү;
- иҗтимагый оешмалар эшчәнлегендә законнарны үтәүгә ярдәм итү;
- иҗтимагый-сәяси вәзгыятьтә тотрыклылыкны, конфессияара һәм милләтара аңлашуны һәм татулыкны саклауга юнәлтелгән чараларны гамәлгә ашыру;
- шәһәрдә социаль-сәяси торышны анализлау һәм аның үзгәрешләрен фаразлау, иҗтимагый-сәяси оешмалар, төрле диннзрнең дини берләшмәләре һәм милли-мәдәни җәмгыятьләр арасында толерант мөнәсәбәтләрне ныгыту;
- Казан шәһәрендә милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне камилләштерүгә юнәлдерелгән региональ һәм шәһәр программаларын гамәлгә ашыру;
- Башкарма комитетның территориаль һәм тармак органнары, шулай ук иҗтимагый оешмалар мөрәҗәгатьләрен карау вазыйфалары йөкләнгән вазыйфаи затлар эшчәнлеген координацияләү;

- иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлек мәсьәләләре буенча оештыру-боеру документларын әзерләү;

- иҗтимагый оешмаларга консультатив ярдәм күрсәтү;

- иҗтимагый оешмалар тармагы буенча Казан шәһәренең халыкара һәм региональ элемтәләрен киңәйтүгә ярдәм итү;

- иҗтимагый оешмалар сораулары буенча аларның эшчәнлеге барышында барлыкка килә торган мәсьәләләрне хәл итүдә кирәкле ярдәм күрсәтү;

- иҗтимагый оешмаларның социаль әһәмиятле эшчәнлегендә ярдәм күрсәтү, шулай ук иҗтимагый-файдалы һәм мәдәни-агарту программаларын гамәлгә ашыру;

- җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре, пикетлар уздыру мәсьәләләре буенча иҗтимагый оешмалар мөрәҗәгатьләре буенча тиешле документларны, шулай ук аларга эш өчен урыннар бирү турындагы үтенечләрне карау һәм әзерләү;

- үз хокук чикләрендә советлар, комиссияләр һәм эшче төркемнәр эшендә катнашу;

- үз хокукы нигезендә методик материаллар һәм тәкъдимнәр ясау;

- иҗтимагый оешмалар мәсьәләләре буенча республика, төбәкара, гомумроссия, халыкара конференцияләрне оештыруда һәм уздыруда ярдәм күрсәтү;

- гомуми һәм җәмгыятьара (милли) җыелышлар, конференцияләр, симпозиумнар, конкурслар, күргәзмәләр, концертлар һәм башка массакүләм чаралар эшендә катнашу;

- тарихи һәм мәдәни ядкарьләр булган биналарны һәм башка объектларны реставрацияләүгә, карап тотуга һәм саклауга бәйле мәсьәләләрне хәл итүдә дини оешмаларга ярдәм күрсәтү;

- гыйбадәт биналарын һәм аларга карый торган җир кишәрлекләре булган корылмаларны функциональ максатларда файдалану өчен дини оешмаларга тапшыруда ярдәм итү;

- иҗтимагый оешмаларга эшчәнлек өчен тигез шартлар тудыру;

- иҗтимагый оешмалар буенча мәгълүмат материалын һәм мәгълүматлар банкын булдыру.

## III. Бүлек хокуклары

3.1. Үз функцияләрен башкару өчен бүлек түбәндәгеләргә хокуклы:

- Башкарма комитетның, предприятиеләрнең һәм оешмаларның, шәһәр учреждениеләренең структур бүлекчәләреннән бүлек функцияләрен башкару өчен кирәкле материалларны һәм белешмәләрне сорарга, алырга һәм билгеләнгән тәртиптә тапшырырга;

- иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлек мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр кертергә;

- бүлек хокукына керә торган мәсьәләләрне карау өчен вәкилләр катнашында Башкарма комитетның кызыксынган структур бүлекчәләре һәм иҗтимагый оешмалары белән киңәшмәләр үткәрергә;

- үз компетенциясе чикләрендә Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең барлык җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарының, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларының үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашырырга;

- шәһәрнең элемтә һәм коммуникацияләр системаларын кулланырга.

3.2. Бүлек үзенә йөкләнгән вазыйфаларны башкару өчен башка кирәкле хокукларга ия.

## IV. Бүлек эшчәнлеген оештыру

4.1. Бүлек эшчәнлеге белән Башкарма комитет Аппараты җитәкчесе тәкъдиме буенча Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан вазифасына билгеләнүче һәм вазыйфасыннан азат ителүче бүлек башлыгы җитәкчелек итә.

4.2. Бүлек хезмәткәрләре үз вазыйфасына Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә Башкарма комитет Аппараты җитәкчесе тарафыннан билгеләнә һәм азат ителә.

4.3. Бүлек хезмәткәрләре Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәрләре булып санала.

4.4. Бүлектәге муниципаль хезмәткәрләрнең хокукый хәле «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ

номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турындагы Татарстан Республикасы кодексы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге уставы, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең башка хокукый актлары, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә.

4.5. Бүлекнең билгеләнгән үрнәктәге бланклары бар.

## V. Бүлек башлыгы

5.1. Бүлек башлыгы бүлекнең эшчәнлеген оештыру һәм тәэмин итү буенча түбәндәге функцияләрне башкара:

- бүлекнең гомуми җитәкчелеген гамәлгә ашыра һәм бүлек хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын билгели;

- максатларны һәм бурычларны үтәүне тәэмин итә;

- үз компетенциясе чикләрендә бүлекнең барлык хезмәткәрләре өчен мәҗбүри булган әмерләрһәм боерыклар чыгара;

- бүлек компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча документларны имзалый һәм визалый;

- бүлек хезмәткәрләренең вазыйфаи инструкцияләрен раслау турында күрсәтмә проектын Башкарма комитет Аппараты җитәкчесенә раслауга кертә һәм аларның үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итә;

- бүлек хезмәткәрләре тарафыннан Башкарма комитетның хезмәт регламенты, вазыйфаи инструкцияләр башкарылуын тәэмин итә;

- коррупцияне кисәтү эшен оештыра, бүлек хезмәткәрләре тарафыннан тыюларның үтәлешен тикшереп тора;

- Башкарма комитет Аппараты җитәкчесенә бүлек хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү, аларны бүләкләү һәм аларда дисциплинар түләтүләр салу турында тәкъдимнәр бирә;

- Башкарма комитет җитәкчесенә билгеләнгән тәртиптә бүлекнең кадрлар резервын формалаштыру турында тәкъдимнәр кертә;

- тиешле органнарга исәп-хисапны исәпкә алуның, үз вакытында бирүнең торышы һәм тапшырылышы өчен җаваплы;

- гражданнарны үз компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча кабул итә, аңлатмалар бирә һәм мәсьәләләрне хәл итүгә киңәш бирә;

- әлеге нигезләмәдән килеп чыга торган һәм гамәлдәге законнарга каршы килми торган башка функцияләрне үти.

5.2. Бүлек башлыгы булмаганда, аның бурычларын үтәү бүлекнең башлыгы урынбасарына йөкләнә.

## VI. Җаваплылык

6.1. Бүлек хезмәткәрләре бурычлы:

- үз вазыйфаи бурычларын белергә һәм тайпылышсыз үтәргә;

- үзләренең сәяси симпатияләре һәм антипатияләре, дәүләт һәм җирле үзидарә органнары, аларның җитәкчеләре эшчәнлегенә карата фикерләре һәм бәяләмәләре турында турыдан-туры яисә читләтеп әйтелгәннәрдән тыелырга;

- лояльлек, гуманлык, социаль гаделлек принципларына нигезләнгән әхлакый нормаларны үтәргә;

- булган хезмәт мәгълүматына карата конфиденциальлек сакларга;

- барлык гражданнарга карата толерантлык, корректлылык, әдәплелек, игътибарлылык, аларның милләтенә, диненә, сәяси юнәлешенә, Россия халыкларының гореф-гадәтләренә хөрмәт һәм сабырлык белдерергә;

- хезмәт бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килүне булдырмау;

- муниципаль хезмәт өлкәсендә һәм коррупциягә каршы тору законнарында каралган муниципаль хезмәт узуга бәйле чикләүләрне үтәргә һәм тыюларны бозмаска;

- хезмәт законнарында, муниципаль хезмәт һәм коррупциягә каршы тору өлкәсендәге законнарда, шулай ук Казан шәһәренең муниципаль хокукый актларында каралган башка бурычларны үтәргә;

- Башкарма комитетның хезмәт регламенты шартларын үтәргә, хезмәт этикасы нормаларын үтәргә, дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне, хезмәт мәгълүматын сакларга.

6.2. Бүлек хезмәткәрләре җаваплылык тота:

- үз исеменнән, үз бүлекчәләре исеменнән ачыктан-ачык яисә конфиденциаль рәвештә бирелгән мәгълүматның дөреслеге өчен;

- куелган таләпләрне һәм функциональ бурычларны тулысынча һәм вакытында үтәмәгән, югарыда күрсәтелгән таләпләрне үтәмәгән өчен;

- кануннар нигезендә алар гаебе белән китерелгән зыян өчен.

**Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Е.А.Варакин**